КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 15 май г.Казань № 397

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Гарантияләр фонды» коммерциягә карамаган оешмасына чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2018 ел, 9 июнь, 438 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Гарантияләр фонды» коммерциягә карамаган оешмасына чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2018 ел, 9 июнь, 438 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 29 сентябрь, 875 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның преамбуласында «2018 – 2020» һәм «2014 – 2020» саннарын шул ук эзлеклелектә «2018 – 2021» һәм «2014 – 2021» саннарына алыштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Гарантияләр фонды» коммерциягә карамаган оешмасына чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибендә:

2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Субсидия Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион

икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының «2018 – 2021 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасының түбәндәге чараларын тормышка ашыру өчен тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законы белән күздә тотылган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә, тиешле финанс елына субсидия бирү өчен бюджет акчасын алучы буларак Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгына (алга таба – Министрлык) билгеләнгән тәртиптә ирештерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә:

кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтүнең гарантияле механизмнарын үстерү;

төбәк гарантияләр оешмасын үстерү;

кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү, шул исәптән моноюнәлешле муниципаль берәмлекләрне үстерү буенча муниципаль программаларны (ярдәмче программаларны) тормышка ашыру кысаларында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү;

моношәһәрләрдә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын тизләтеп үстерү максатларында, төбәк гарантияләр оешмасын үстерү;

Татарстан Республикасында хакимият белән бизнесның үзара хезмәттәшлеге системасын оештыру.»;

5 нче пунктта «2018 – 2020» саннарын «2018 – 2021» саннарына алыштырырга;

11 нче пунктның уникенче абзацында «2018 – 2020» һәм «2014 – 2020» саннарын шул ук эзлеклелектә «2018 – 2021» һәм «2014 – 2021» саннарына алыштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин